| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**<br>**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

07.02.2020 Сарсак-Умга авылы № 61-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 36-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 36-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче өлешнең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 0,3% - торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокук өлешеннән тыш яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) күчемсез милек объектларына (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)»;

1.2. 2нче өлешнең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 0,3% эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге "Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган" гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләре карата»;

1.3. 6нчы өлештә «салым чоры» сүзләрен «хисап чоры» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш һәм Россия Федерациясе Салым кодексы нормалары нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга  авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет, социаль Законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе — Т.С. Николаева